СОВЕТ ВЕРХНЕОШМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
с..Верхняя Ошма, д.54 а, с. Верхняя Ошма,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422163

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЮГАРЫ УШМА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Совет ур., №54а нче йорт,ЮгарыУшма авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422163

тел.(факс): (85563) 2-32-36; e-mail: Voshm.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение | Карар
24 сентябрь 2018 ел | № 2-36

## Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Югары Ушма авыл җирлеге территориясендә җирле референдумны билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 ел, 12 июнь, 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, 2004 елның 23 мартындагы 23-ТРЗ номерлы «Җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Югары Ушма авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Югары Ушма авыл җирлеге Башкарма комитетының2017 елның 17 сентябрендәге «Референдум үткәрү инициативасы турында» 24 номерлы карары, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлеге Советының 2014 елның 2 апрелендәге №2-36 карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Югары Ушма авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын җыю һәм алардан файдалану тәртибе турында Нигезләмә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлеге Советының 2014 елның 2 апрелендәге 2-36 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю һәм куллану тәртибе турындагы Нигезләмә (17.09.2018 № 5-35 карар редакциясендә) Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлеге Советы
КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Югары Ушма авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдумны 2018 елның 18 ноябренә билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган түбәндәге сорауны расларга: «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби

хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2019 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

1. 1. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмиятле автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру;

- Югары Ушма т.п , Иске Завод авылы т.п., Ак Чишмә т.п. , Хәсәнша авылы т.п. ,Комазан Урманчылыгы т.п. урамнарында юлларны вак таш җәеп ремонтлау;
- авыл җирлегенә караучы юлларны тигезләү һәм кардан чистарту.

2. 2.Җирлек торак пунктлары чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү:

Югары Ушма авылында янгын гидранты урнаштыру.

3. Җирләү урыннарын карап тоту һәм ритуаль хезмәтләр оештыру:

Алкино т.п. зираты территориясен койма белән әйләндереп алу.

«ӘЙЕ» «ЮК».

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Дүсмәт авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының http://mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. . Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлеге башлыгы И.З.Исмагилов йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Югары Ушма авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе И.З.Исмагилов